*Инсафутдинова М. Т. (РИИ, Казань)*

# ФДБСНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУДА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ

**Аннотация:** В данной статье даны основные требования к проектной деятельности в рамках ФГОС, направленного на развитие универсальных учебных действий. Также в статье рассматривается метапредметный результат, основные требования проектной работы учащихся.

**Ключевые слова:** проектная деятельность, научно-исследовательская работа, ФГОС, универсальные учебные действия, метапредметный результат.

**In the implementation of Federal state educational standards of the project activity on the lessons of the Tatar language and literature.**

**Abstract:** In this article the main requirements to design activity within FGOS aimed at the development of universal educational actions are given. Also in article the metasubject result, the main requirements of the project work of pupils is considered.

**Key words:** design activity, research work, universal educational actions, metasubject result.

«Укымак – фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк.

Укымак - үз янында булып торган нәрсәләрдән бигрәк,

фикерләрне булачакларга сузмак»

Габдулла Тукай.

Бүгенге көндә заманча укыту таләпләренең иң мөһиме – укучыларның фикерләү сәләтен үстерү. ФДБС таләпләре буенча да белем бирү процессында җәмгыять өчен төрле яклап үскән шәхесләр тәрбияләү мөһим урын алып тора. Бу бурычларны татар теле һәм әдәбияты укытучысы нинди юллар белән тормышка ашыра ала? Укучыларның гомуми үсешенә йогынты ясарлык нинди чаралар кулланырга мөмкин соң?

Әлеге чараларның берсе – укучыларны фәнни-тикшерү эшләренә җәлеп итү. ФДБС таләпләреннән чыгып аңлаткангда, балада фәнни эшкә кызыксыну уяткан вакытта, универсаль уку гамәлләренең барсысы да эшкә җигелә. Шәхескә кагылышлы нәтиҗәлелек тә, метапердмет, предмет буенча булган нәтиҗәлелек тә бу очракта чагылыш таба, әлбәттә. Икенче төрле әйткәндә, стандартларга нигезләнеп укытканда, төп максатыбыз – укучыны тормышка әзерләү, дөньяда үз урынын табарга ярдәм итү. Бүген ул укучы булса, иртәгесе көндә ул – студент. Нәкъ менә шуңа күрә фәнни-тикшеренү эшләре, ягъни проектлар белән шөгыльләнгән укучыга югары уку йортларында укуы бермә-бер ансатрак булачагын дәлилләп тә торырасы юк.

Укучының фикерләү сәләтен үстерү максатыннан, аны фәнни тикшеренү эшләренә этәрү, өндәү заман таләпләренә туры килә. Әлбәттә, укучыларны проект эшләренә җәлеп итү бик зур мөмкинлекләр ача: предмет буенча белемнәрен арттыра, яңача фикерләргә өйрәтә, укучыларның сөйләм телен үстерергә ярдәм итә. Әдәбият белән кызыксындыруда да аеруча нәтиҗәле алым булып тора.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проект яки фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнү тикшерү ысулын игътибар үзәгенә куя. Бу урында галимә Д. Ф. Заһидуллинаның тикшерү ысулы турындагы фикерен искә төшерик: «Тикшерү методының максаты – укучыларны әдәби әсәр белән мөстәкыйль танышырга, аны анализларга күнектерү, әдәби һәм форма эшләнешен тоярга, эстетик зәвыкны үстерергә, әдәби әсәрне бәяләү критерийларын билгеләргә өйрәтү. Ысул теоретик белемнәрне гамәлдә куллана белүне, әсәрне мөстәкыйль анализлау һәм нәтиҗәләр чыгаруны таләп

итә. Тикшеренү ысулы бик мөһим вазифалар башкара. Ул, беренчедән, фәнни-тикшеренү ысулларын эзләү һәм алардан файдалану барышында әлеге ысуллар белән эшләргә өйрәтә. Икенчедән, иҗади эшчәнлек сыйфатларын калыплаштыра. Өченчедән, мондый эшчәнлек белән кызыксыну уята. Дүртенчедән, тикшерү ысулы аңлы рәвештә белем алуга китерә. Тикшеренү ысулы укучы эшчәнлеген үзәккә куя» [4, с. 20].

Укучыларда фәнгә кызыксыну, иҗатка ашкыну тудыру өчен кызыклы һәм стандарт булмаган дәресләр үткәрү зарури: дәрес-экскурсия, дәрес-концертлар, әңгәмә-дәресләр, семинар-дәресләр, сәяхәт-дәресләр, театраль дәресләр, дәрес-конференция, төрле очрашулар һ.б.

Хәзерге көндә инновацион технологияләр яңа төр дәресләр үткәрергә мөмкинлекләр ача. Белгәнебезчә, стандартлар буенча укыткан вакытта, дәрестә укучы эшчәнлеге иң югары дәрәҗәдә оештырылган булырга тиеш. Әдәбият дәресләренә фәнни-тикшеренү, проект эшләрен кертеп җибәрү - иң отышлы чара-алымнарның берсе. Укучыларны фәнни тикшеренү эшенә җәлеп итү укытучыдан да зур әзерлек сорый. Остаз укытучы, көтелгән нәтиҗәне күз алдында тотып, һәр этапта дөрес юнәлеш бирергә сәләтле булырга тиеш. Нинди генә эш башкарылса да, ахыргы нәтиҗә әүвәл куйган максатның, бурычларның дөрес билгеләнүенә бәйле. Эзләнү-тикшеренү яки проект эшендә тикшеренүченең нинди сорауга җавап эзләве ачык чагылырга тиеш. Дөреслекне фактларга бәйле аңлатмалар расларга зарур. Нәкъ менә шуңа күрә тикшерү эшенең бу өлкәсенә аеруча җитди карарга киңәш ителә.

Проект эшчәнлеген оештыруда эшне планлаштыру этаплары:

1.Проектның темасын, структурасын, эчтәлеген сайлау.

2. Проблеманы ачу өчен сораулар уйлау (Без моны ничек эшлибез? дигән сораудан түгел, ә Ни өчен эшлибез? Нинди проблеманы хәл итү максатыннан эшлибез? дигән сорауларга җавап эзләүдән башланып китә.)

3.Тиешле мәгълүматны табу юлларын ачыклау. Катнашучыларның вазифаларын билгеләү (ата-аналар эшчәнлеге, бала эшчәнлеге, укытучы эшчәнлеге, башка фән укытучыларның ярдәме)

4.Проект туплау ( мәгълүмат җыю, проблеманы тикшерү, ачу, аны чишүдә дөрес вариантны сайлау, эшне бизәү).

5. Проектны тәкъдим итү, яклау формаларын уйлау. Төрле формада эшләргә була.

Мәсәлән, сәяхәт, агитбригада чыгышы, афиша, реклама, плакат, буклет, рольле уен, мини-спектакль, телевизион тапшыру, күргәзмә, зал белән уен, интервью, әдәби персонажлар диалогы.

6. Проектны бәяләү. Урыннар билгеләп, ярышка әйләндерү киңәш ителми. Берничә номинация тәкьдим итеп һәм һәр проект нинди дә булса бер номинациядә җиңәрлек итеп оештыру нәтиҗәле һәм отышлы булачак.

7. Проектның перспективасын билгеләү. Иң мөһиме – игътибарсыз калмаска тиеш. Аеруча әһәмиятле фактор – балалар үз эшләренең кирәклегенә төшенсеннәр һәм аның башка кешеләргә шатлык, рәхәтлек китерүен күрсеннәр.

Мөгаллим җитәкчелек итә, күрсәтмәләр белән тәэмин итә, һәр этапны күздә тота, кирәк булганда, ярдәм күрсәтә. Тема сайлаганда, укучылар үзләре мөстәкыйльлек күрсәтәләр. Алар үзләренә якынрак булган темаларга тукталырга телиләр. Тема шулай ук конкрет, актуаль, оригиналь һәм үти алырлык булырга тиеш. Югары сыйныфларда күп кенә очракта укучылар теманы үзләре дә формалаштырырга мөмкин.

Шуннан соң төп этап башланып китә – әдәбият өлкәсе булса, әдәби әсәрләрне өйрәнү, төп проблемага төрле яктан якын килү, беренчел фикерне, идеяне ачыклау, тупланган нәтиҗәләргә бәя бирү, анализлау, чагыштырулар уздыру. Тикшеренү, анализ, синтез методын куллану укучыларның темага карашларын үзгәртә, аларны тагы да мавыктырып җибәрә. Алар үзләрен бу тикшеренү эшендә баш катнашучылар булып китәләр, үзләренә ышану хисе көче арта бара, шуның белән бергә күпсанлы әдәби әсәрләр белән танышалар, материалны туплап нәтиҗә ясыйлар, галимнәрнең хезмәтләре белән эшләргә өйрәнәләр, башка фән укытучылары белән дә элемтә булдыруы ихтимал, яңа ачышлар, яңа танышулар һ.б

Проект эше уңышлы алып барылсын өчен, теманы дөрес сайлап алу мөһим. Фәнни хезмәт актуаль әһәмиятле темага башкарылырга, тикшеренүченең индивидуаль теләкләренә һәм мөмкинлекләренә туры килергә тиеш. Тема сайлау – фәнни эшнең гаять җитди һәм җаваплы беренчел өлеше. Нинди генә тема алынса да, ул шактый озак һәм киеренке эшләүне, бөтен көч, белем, сәләтеңне бирүне таләп итә торган олы мәсьәлә. Эшнең исеме эшләгән эшне төгәл һәм анык итеп атарга тиеш. Диалект, тарих, фольклор, онамастика те-

малары күңелгә якын темалар. Татар әдәбиятын рус әдәбияты белән чагыштырмача өйрәнү, татар телен рус теле, инглиз теле, төрки телләр белән чагыштырып карау, халык авыз иҗаты әсәрләрен чагыштырып күзаллау кызыксындыргыч нәтиҗәләр бирә. Бу очракта предметара бәйләнеш булуы мәслихәт.

Татар теле һәм әдәбиятын өйрәнгәндә, түбәндәге төрдәге проектларны кулланып була:

-тикшеренү: хезмәтнең актуальлеген нигезләү, тикшерүнең максатын әйтү, бурычлар кую, аларны чишү юлларын билгеләү;

-иҗади: әдәби-музыкаль кичә яки бәйрәм үткәрү өчен сценарий төзү, «Татар милли бәйрәмнәр», «Татар телем – иркә гөлем» бәйрәме һ.б;

-гамәли юнәлешле: һәр укучының, төркемнең бөтен эшчәнлеген яхшы нәтиҗәләргә ирешү максатыннан чыгып планлаштыру. М-н, төрле темаларга рәсемнәр, презентацияләр, коллажлар, кластерлар ясау «Мин һәм минем гаиләм», «Безнең туган ягыбыз», «Табигатьне саклыйк», китапчыклар чыгару, килеш кушымчалары буенча ярдәмлек чыгару,"Милли киемнәр» дигән темага презентация ясау, бер төркемгә билгеле бер темага табышмаклар табып килергә, икенче төркемгә – китапчык ясап, табышмаклар туплarga, өченчеләренә - темага карата табышмак иҗат итәргә тәкъдим итеп була;

-мәгълүмати: темага караган мәгълүматларны җыю, шуларны катнашучыларга тәкъдим итү, фикерләр белән уртаклашу, әңгәмә, йомгаклау. Дәресләрдә мини-проектлар оештырырга мөмкин, мәсәлән, котлаулар язу, көндәлек режимны төзү һәм сөйләү, минем яраткан шагыйрем, әдәби героем, китабым турында мини эзләнү проектын ясау, гаилә портфолиосы, шәҗәрә агачын ясау);

-предметара (берничә предметка нигезләнү). Мәсәлән, «Татарстан елгалары», «Дәүләт символлары», «Сәламәтлек – зур байлык», «Файдалы үләннәр», «Татарстан картасы» һ.б.

Нәтиҗә итеп, шуны әйтәсе килә: Һәр кеше яшәеш чорына нинди дә булса нәтиҗә ясарга тиеш. Бүгенге, педагогик тәрбия концепцияләре яңарган, әхлакый тәрбия бирүнең әһәмияте үсеш алган шартларда, шәхестә рухи-әхлакый тойгыларны үстерү мәсьәләсе аеруча мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Яңа буын белем бирү стандартларында да моңа аерым урын бирелә. Бүгенге буын укучылары XXI йөзнең катлаулы чорында яши. Мондый шартларда мөгаллимнәр

әхлак көче, белем, акыллылык, әхлак тәрбиясен тормышка ашыра алырлык теория таба алырга тиешләр. Укучылар дөрес юлны сайлый, усаллык белән көрәшә алу кебек күнекмәләргә ия булырга тиешләр. Кешенең әхлагы булмаса, ул үзе дә, аның тирә-янындагы кешеләре дә бәхетсез була. «Әхлак берлә әдәбият бергә булыр, бер халыкның әдәбияты нинди булса, әхлагы да шул рәвештә булыр» – дип яза бөек мәгърифәтче Р.Фәхретдинов. Шуңа күрә проект эшчәнлеген дә без шушы юнәлештә алып барырга тиешбез. Балаларны үз юлын дөрес итеп таба белергә, тормыш максатларын куеп, планнарга, хыялларга ирешергә, мәсъәләләрне чишә белә торган көчле рухлы шәхес итеп тәрбияләргә тиеш. Бу максатка ирешү өчен әлеге дә баягы проект эшчәнлеге зур роль уйный, дип әйтергәкирәк.

Әдәбият:

1.Белем күтәрүче тыңлаучыларның проекты. Төп гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучылары. Автор-төзүче. – Шәйхелисламов Р.Ф., Хуснуллина З.М., Зинина Н.Н., Земскова В.Н. –Казан: ПМЦ ПК и ППРО КФУ, 2015. –158 б.

2. Вәлиева Ф. С. Саттаров Г. Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан, 2000.- 475 б.

3. Заһидуллина Д. Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2004.

4.Заһидуллина Д. Ф., Ибраһимов М.И., Әминова В. Р. Әдәби әсәргә анализ ясау. – К.: Мәгариф, 2005.

5. Исмәгыйлова С.Г. Укытучының фәнни эшчәнлеге. «Мәгариф» журналы, 2011 №12, – 3 б. 96 б.

6. Сәмигуллин Г.Х. Татар әдәбиятын системалы укыту: эзләнүләр һәм тәҗрибә. – Яр Чаллы, 2006. – 94 б

7. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогика. – Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2004. – 542 б.

8. Хайдарова Р.З. Научно – педагогические аспекты билингвального образования в Республике Татарстан. –г. Набережные Челны,2006. –197с.

9. Харисов Ф. Ф. Харисова Ч. М. Татар теленнән күнегүләр һәм тестлар. – Казан, 2006. – 183 б.